**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№6061**
**02.11.2022**

Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә җирләү эшен оештыру турында» 2017 елның 21 апрелендәге 2465 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Күмү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1 өлешнең 23 пункты, шәһәр Уставының 41 статьясындагы 9 өлешнең 13 пункты, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә җирләү эшен оештыру турында» 2017 елның 21 апрелендәге 2465 номерлы карарына (Башкарма комитетның 2018 елның 10 июлендәге 3841 номерлы, 2019 елның 28 июнендәге 3288 номерлы, 2022 елның 1 сентябрендәге 4429 номерлы карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә ритуаль хезмәтләрне оештыру һәм җирләү урыннарын карап тоту тәртибенең 49 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«49. Җирләү, зират территориясеннән рациональ файдалануны исәпкә алып, эзлекле тәртиптә башкарыла. Участок, аның күләме һәм турыдан-туры күмү урыны, вафат булучының һәм вафат булучыны күмү бурычын үз өстенә алган затның ихтыярын исәпкә алып, вәкаләтле орган тарафыннан билгеләнә.»;

2) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә ритуаль хезмәтләрне оештыру һәм җирләү урыннарын карап тоту тәртибенә 1 нче кушымтада:

- 1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Вафат булучыны җирләүне гамәлгә ашыру бурычын үз өстенә алучы үз өстенә йөкләмә ала: рөхсәттә күрсәтелгән вакытта зиратка керүне гамәлгә ашырырга; санитария һәм экология таләпләренә туры китереп, җир эшләрен

башкарырга, җирләү урынын һәм аның янәшәсендәге территорияне карап тотарга; күрше каберләргә һәм кабер өсте корылмаларына зыян китергән өчен милек җаваплылыгы алырга.»;

- 3 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«үлү турында таныклык күчермәсе; Бөек Ватан сугышы ветераны таныклыгы күчермәсе, хәрби хәрәкәтләр ветераны таныклыгы күчермәсе (әгәр булса), җирләү турында таныклык, минем паспорт күчермәсе, җирләүне башкаручы юридик затны (шәхси эшмәкәрне) дәүләт теркәве турында таныклык. Гаризага персональ мәгълүматларны эшкәртүгә ризалыгымны терким.».

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе башлыгы И.Н. Гайнуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы И.С. Зуев